**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

________________ ПР-171 от 18.09.2024 № ___

Иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Чуракай авыл җирлеге, Чуракай авылы, Совет урамы, 57 йорт - Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Чуракай авыл җирлегендә индивидуаль торак төзелеше (Ж1) кагыйдәләре зонасында «Мәдәнит объектлар» адресы буенча урнашкан, 16:04:240101:130 кадастр номерлы, 2 300 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлауларны билгеләргә.

2. Иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

1) Хәйдәров Рафаэль Рәиф улы
2) Галиәхмәтов Айнур Кәрим улы
3) Зәйнетдинов Булат Рифат улы
4) Шәехова Зәлия Мирзаһит кызы

3. Чуракай авыл башкарма комитетына иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручыга җирле үзидарә турындагы законнар, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) үткәрүне 23.09.2024 елга кадәр тәмамланырга тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, https://aktanysh.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.Т. Демидовка йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов